| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ЭБАЛАКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЯБАЛАКАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«27» сентябрь, 2024 ел Ябалак авылы № 84

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге Советының«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 32 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлегенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге Советының«Физик затлар мөлкәтенә салым турында»2014 елның 19 ноябрендәге 32 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2пунктны түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча белән тулыландырырга:

«6)

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган исемлеккә кертелгәнгомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артык һәм алардагы бүлмәләрдә булган административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләренә (комплекслар) карата 1,2%.».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән 1 айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә һәм 2027 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Ябалак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
Ябалак авыл җирлеге Башлыгы М.Ф.Гизатуллина